# КАРАР

**“13” ноябрь 2021 ел** **№7**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 13 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган граждannardan тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Төньяк урамының 30 нчы йортыннан 38 нче йортына кадәр, Сәгъдуллин урамының 44 нче йортыннан 52 нче йортына кадәр, Яшьләр урамынын 6 нчы йортыннан 10 нчы йортына кадәр, Яр буе урамының 1 нче йортыннан 4 нче йортына кадәр юлга нигез салу һәм вак таш җәю;
- Шушмабаш авылында юл-урам челтәренең юл полотносында чокырларны ремонтлау;
- материал сатып алып Сәгъдуллин урамы 46а адресы буенча су башнясын төзекләндерү эшләре үткәрү;
- Шушмабаш авылында суүткәргечне ремонтлау;
- Шушмабаш авылында кое өчен 1 данә насос сатып алу;
- Шушмабаш авылында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- бензинда эшли торган кар чистарткыч сатып алу- 1 данә

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә»

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены йомгаклау беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 703 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 361 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 342 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 19 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Төньяк урамының 30 нчы йортыннан 38 нче йортына кадәр, Сәгъдуллин урамының 44 нче йортыннан 52 нче йортына кадәр, Яшьләр урамынын 6 нчы йортыннан 10 нчы йортына кадәр, Яр буе урамының 1 нче йортыннан 4 нче йортына кадәр юлга нигез салу һәм вак таш җәю;
- Шушмабаш авылында юл-урам челтәренең юл полотносында чокырларны ремонтлау;
- материал сатып алып Сәгъдуллин урамы 46а адресы буенча су башнясын төзекләндерү эшләре үткәрү;
- Шушмабаш авылында суүткәргечне ремонтлау;
- Шушмабаш авылында кое өчен 1 данә насос сатып алу;
- Шушмабаш авылында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- бензинда эшли торган кар чистарткыч сатып алу- 1 данә

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1б йорт, Мәктәп урамы, 8 йорт, Мәктәп урамы, 5 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов